РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«21» март 2025г. г. Альметьевск № 164

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы»муниципаль берәмлегенә тапшыру турында» 2021 елның 28 сентябрендәге 47 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында «Татарстан Республикасы Законының 11 һәм 13 статьяларына һәм» Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»2024 елның 17 октябрендәге 84-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында» 2021 елның 28 сентябрендәге 47 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәр Советының 2022 елның 28 февралендәге 63 номерлы, 2023 елның 21 декабрендәге 135 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

1.1. 3 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге түләүле автомобиль юллары, күрсәтелгән автомобиль юлларының түләүле участоклары буйлап транспорт чаралары йөргән өчен түләүне исәпләү методикасын һәм аның максималь күләмен билгеләү;»;

1.2. 13 пунктның өченче абзацында «массакүләм спортны үстерү,» сүзләрен «массакүләм спортны үстерүгә һәм аннан файдалана алуны тәэмин итүгә ярдәм итү, үстерү» сүзләренә алмаштырырга»;

1.3. 13 пунктның унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәренең спорт җыелма командалары өчен спорт резервы әзерләүне тәэмин итүдә катнашу».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлмәт шәһәр Советының бюджет-финанс мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Мусин Р.Ф.).

Шәһәр башлыгы
вазыйфаларын башкаручы И.Р. Баһманов

«АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ»